СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 7-14 от «27» июня 2022 г.

Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 ноябрендәге 7-29 карары (2019 елның 28 мартындагы 6-32 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3.2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне әзерләгәндә, җирле үзидарә органының кадрлар бүлеге вазыйфаи затлары мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә биргән муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә үткәрергә, аннан язма аңлатмалар алырга, ә җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә аның урынбасары, махсус шуңа вәкаләтле вәкил, билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга, «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланырга, шул исәптән запрослар җибәрергә хокуклы. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар килгән көннән алып җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Сораулар юлланган очракта мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән

алып 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән артмаска тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе — А.П. Иванов